**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

« 08 » 04   2024 ел Яр Чаллы ш. № 902

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү методикасы, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берләшмәсе» коммерциясез партнерлыгының 2024 елның 13 февралендәге 79 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» бәяләмәсе нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

- ялгыз яшәүче кеше өчен – 944 073 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 1888 146 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 2 832 219 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 776 292 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен- 4 720 365 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 5 664 438 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 608 511 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 552 584 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган җыелма керемнең максималь күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен - 31 725 сум 29 тиен;

- ике кешедән торган гаилә өчен - 31 725 сум 29 тиен;

- өч кешедән торган гаилә өчен – 31 725 сум 30 тиен.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарда күрсәтелгән максималь чик күрсәткечләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин